| СОВЕТ<br>НИЖНЕВЯЗОВСКОГО<br>ГОРОДСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ<br>ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЗЕЛЕНОДОЛЬСК<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>КАРАМАЛЫ ТАУ<br>ШӘҺӘР ҖИРЛЕГЕ<br>СОВЕТЫ |
|---|---|

**РЕШЕНИЕ**
**16.08.2023**

Карамалы Тау штп

**КАРАР**
**№ 164**

Түбән Карамалы Тау шәһәр җирлеге Советының 2021 елның 12 июлендәге 53 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Түбән Карамалы Тау шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге территориясен төзекләндерү кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында (Түбән Карамалы Тау шәһәр җирлеге Советының 2022 елның 23 августындагы 110 номерлы карары белән кертелгән үзгәрешләр белән)

«Хайваннар белән җаваплы мөгамәлә итү һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2018 елның 27 декабрендәге 498-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Түбән Карамалы Тау шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге Уставы белән, Зеленодольск муниципаль районы Түбән Карамалы Тау шәһәр җирлеге Советы **карар кылды:**

1. Түбән Карамалы Тау шәһәр җирлеге Советының 2021 елның 12 июлендәге 53 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Түбән Карамалы Тау шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге территориясен төзекләндерү кагыйдәләренә (Түбән Карамалы Тау шәһәр җирлеге Советының 2022 елның 23 августындагы 110 номерлы карары белән кертелгән үзгәрешләр белән) (алга таба – Кагыйдәләр) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Кагыйдәләрне түбәндәге эчтәлектәге 1 нче кушымта белән тулыландырырга:

«Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Түбән Карамалы Тау шәһәр тибындагы

поселогы» муниципаль берәмлеге территориясен төзекләндерү кагыйдәләренә 1 нче кушымта, Түбән Карамалы Тау шәһәр җирлеге Советының 2021 елның 12 июлендәге 53 номерлы карары белән расланган

**Исемлек**
**Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Түбән Карамалы Тау шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге территориясендә хуҗасыз хайваннарны кайтару тыела торган урыннарга»**

1. Балалар уен һәм спорт мәйданчыклары, актив спорт төрләре белән шөгыльләнү өчен спорт мәйданчыклары, ачык һавада спорт уеннары өчен билгеләнгән мәйданчыклар.

2. Җәмәгать территорияләре (парклар, скверлар территорияләре, күпләп ял итү урыннары, гомуми файдаланудагы су объектларының яр буйлары).

3. Мәгариф оешмалары һәм сәламәтлек саклау оешмалары территорияләре, күрсәтелгән оешмаларга якын территорияләр.

4. Мәдәният һәм сәнгать объектларына якын территорияләр.

5. Җәмәгать туклануы оешмаларына, сәүдә объектларына, стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру урыннарына якын территорияләр.

6. Зират.».

2. Хайваннарны элеккеге яшәү урыннарына хуҗасыз кайтару турында Карар кабул итүгә вәкаләтле затларның түбәндәге исемлеген билгеләргә:

- Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Түбән Карамалы Тау шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге башлыгы;

- Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Карамалы Тау шәһәр җирлеге башкарма комитеты җитәкчесе.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында урнаштырырга (http://pravo.tatarstan.ru) Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Зеленодольск муниципаль районының мәгълүмати сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә, шулай ук түбәндәге адреслар буенча мәгълүмат стендларында: Карамалы Тау ш.т.п., Беренче Май ур., 70 йорт, ҖҮИ административ бинасында мәгълүмат стенды, Беренче Май ур., 70 йорт (ҖҮИНЕҢ административ бинасы).

Җирлек башлыгы,
Совет Рәисе А.М. Гыйниятов